ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Казан шəһəре муниципаль берəмлеге территориясе чиклəре һəм аның статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һəм «Чаллы шəһəре» муниципаль берəмлеген төзү, аның чиклəрен билгелəү һəм аңа шəһəр округы статусын бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгəрешлəр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дəүлəт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

## 1 статья

«Казан шəһəре муниципаль берəмлеге территориясе чиклəре һəм аның статусы турында» 2004 елның 15 сентябрендəге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дəүлəт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 8 – 9; 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (VI өлеш); 2012, № 1; 2014, № 12 (IV өлеш), аны түбəндəге редакциядə бəян итеп, үзгəреш кертергə:

«1 статья. **Казан шəһəре муниципаль берəмлеге территориясе чиклəре турында**

Казан шəһəреннəн (административ үзəк) һəм аның янəшəсендəге терртиториялəрдəн торучы Казан шəһəре муниципаль берəмлеге территориясе чиклəрен карта-схема (əлеге Законга 1 нче кушымта) һəм чиклəрнең картографик тасвирламасы (əлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендə билгелəргə.».

## 2 статья

«Чаллы шəһəре» муниципаль берəмлеген төзү, аның чиклəрен билгелəү һəм аңа шəһəр округы статусын бирү турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дəүлəт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш), аны түбəндəге редакциядə бəян итеп, үзгəреш кертергə:

«2 статья. **«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләре турында**

Чаллы шәһәреннән (административ үзәк) торучы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендә билгеләргә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 26 май
№ 30-ТРЗ